**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

_31.08.2022_ _ 755-п _

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын туктату, шул исәптән вакытыннан алда, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 15 мартындагы 192-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын туктату, шул исәптән вакытыннан алда, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 15 мартындагы 192-п номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 4 ноябрендәге 917 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 6 июнендәге 522 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибендә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын туктату, шул исәптән вакытыннан алда, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибендә:

1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«11) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының мәҗбүри көчү очраклары һәм (яки) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне

мәҗбүри үзгәртеп рәсмиләштерү нигезләре булып торган шартлар барлыкка килүе, әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының мәҗбүри күчү һәм (яки) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне мәҗбүри үзгәртеп рәсмиләштерү шартлары үтәлмәсә.»;

1.7 пунктның 1 пунктчасында «, ә чит ил заты өчен – тиешле чит ил дәүләте законнары нигезендә салым түләүченең тәңгәллек номеры аналогы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктның 4 пунктчасында «1, 5, 8 – 10 пунктчаларда» сүзләрен «1, 5, 8 – 10, 11 пунктчаларда» сүзләренә алмаштырырга;

3.10 пунктның беренче абзацында «1, 5, 8 – 10 пунктчаларда» сүзләрен «1, 5, 8 – 10, 11 пунктчаларда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын, шул исәптән вакытыннан алда, туктату, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү комиссиясе составында:

Полушин Владислав Леонидовичны комиссия составыннан чыгарырга;

комиссия составына Тюплина Юлия Константиновнаны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының мәгълүмати геологик ресурслар һәм геологик тирәлекне мониторинглау бүлеге җитәкчесен кертергә.

2. Хокукый тәэмин итү бүлеге әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

Министр А.В. Шадриков